# КИЯҮ

Атын туарырга дип каршы чыккан угылына да Садыйк абзый:

— Исән тордыңызмы, угылым? Хезмәтче тырмага киттеме? — дип эндәште. Кайнап тора торган самавырга урын хәзерләргә кушып, картына комган күтәреп каршы чыккан Мәрфуга абыстайның: «Исән кайттыңмы, карт? Сатулар яхшы булдымы?»— диюенә дә: «Аллага шөкер»,— дип, күңеллеләнеп җавап бирде. Ишек төбенә чыгып: «Әти, миңа зиякләр алып кайттыңмы?» — дигән кызына ул тагы йомшаграк тавыш белән:— Кайттым, кызым, кайттым,—диде. Үзе озын гына иттереп кызыны күзе белән сөзгәннең соңында, уеның очыны бетергән кеби иттереп, тагы: — Кайттым, кызым, кайттым. Аллы-гөллеләрен алып кайттым,— диде.

Чәй янында да Садыйк абзый бик йомшак кылынп, йомшак сүзләр сөйләп утырды. Чәйдән сон тәһарәткә су сораганда да:

— Килен, бәпкәм, суың бармы? — дип эндәште. Угылына да, йомшак кына иттереп, ындыр табагының ярылмаганмы икәнене барып карарга кушты. Угылы, ындырдагы былтыргы зур кибәнне сугарга уйлый торгандыр әле дип төшенеп:

— Әле бераз көтәргә кирәк. Ике сука арасында акчага сатсаң да бәһасе кыйбат була, бурычка өләшсәң дә кешенең өзек чагы була!—диде.

Ләкин Садыйк абзый, аның сүзене ишетмәгән кеби:

— Баш көн бүген, тәһарәтең булса, бабаңа да Коръән укып кайт,—дип, сүзен бетерде. Угылы чыгып киткәч тә, үзе: — Карчык, мин югары очка менеп төшим әле. Шул бүрәнәләр тузылып яталар. Әхмәди угланнары эшсез булса, мунча салдырып ташлыйм дим. Белмәссең, Саҗидә дә җиткән, тәкъдире булса, биреп тә куярмыз. Кара мунча белән кияү, кода сыйламассың инде,— диде.

Мәрфуга абыстай, Садыйк абзыйның бөтен кылынышында әллә нинди ят бер хәрәкәт күргәнгә:

— Әллә, карт, бер-бер йылы хәбәр йышеттеңме? — диде. Карт, китәргә дип ашыккан кеби булса да, сөальле иттереп, бүлмәгә карады. Мәрфуга абыстай: «Юк, юк, җиңгәсе янында, токмач кисә»,—дигәч:

— Түбән авылның Шәрәфи абзый белән чәйгә кердек. Беләмсең, безнең авылның Фәхриләрнең Әсмасының иренен атасы белән бертуган, былтыр Садрыйларга килгән иде? Камалы тун киеп йөри? Шул сөйләп торды: «Иске мөәззиннең угылына тамга җыйдык, хәзер имтиханга китте. Бик яхшы бикәч кирәк иде. Үземезнең авылда кызлар булса да, әле безнең хатыннар: Чәүкә Вәли кызыны, Кәкре Шакир сеңелесене ничек остазбикә итеп ашымның түренә утыртыйм, диләр. Мөәззин үзе дә шул фикердә: «Мин әле, Садыйк абзый, эчемнән генә уйлап, синең белән сөйләшим дигән идем. Мөәззиннең анасына башка бер энесе генә. Минме, минем карчыкмы, җомга укыгач чәй эчәргә генә барып килсәк, көтелмәгән кунак кайдан килде дип исеңез китмәсен дим генә»,—диде. Шуның белән әлегә бетсә дә, күрешкәндә тагы шуны аңлатты. Мин дә: «Без сезнең кеби кадерле кунакны бик яратамыз»,— дидем. Көлә-көлә аерылыштык. Җыйнаграк торырга кирәк, карчык. Мин, алай-болай кунак-төшем булса дип, оныны-тозыны алып кайттым,— диде.

Мәрфуга абыстай, эченнән сулап:

— Алла хәерле кылсын. Кеше өчен үстергән бала бер кешегә китми хәле юк инде,— диде дә үзе эченнән: «Юкка өченче көн ике пар тозлы казны Сафа хатынына саттым. Йомыркам гына йитсә ярар иде. Җәй үтеп китә, җиһаз дия-дия, йомырка да җыя алмадым»,— дип уйлады. Аның күңеленә угылының туе килеп төште: «Әйе, туй барысы бер. Ләкин кыз алганда кукраеп кодагый булып түрдә утырасың, кодагый, кодачаларның ашларын бик яхшы булган дип, яратмаганны күрсәтеп тора торган төсле мактыйсың. Бунда —аяк өстендә син, түр башында башкалар. Тагы, мулла-мөәззин белән кода булышкач башкача: ширбәте, катламасы гына җитми, как-төш тә кирәк! Кияүгә бүләк бер как-төш, мәҗлескә бер, кияү белән кызга бер. Мәҗлескә дигәне алтмыш йомыркадан, кияүгә дигәне кырык-илледән ким булмаска кирәк, бәлки ул, анда как-төш ашарга дуст-ишен җыяр. Кыз катына дигәне — утыз йомырка!

Хезмәтченең ике күзе, киленнең бер күзе сукыр, диләр, дөрест! Йомыркаларымны каргадан ашатып бетерде, әллә ничә тавыгымны оясыннан биздерде»,—диде. Ул фикер бетмәде, бирнәләр хәтеренә килде: «Каенанасы бар, ди. Мулла-мөәззин белән катышкач, аңар кәшимир күлмәк кирәк инде. Тагы кодачалары-фәләннәре бардыр инде. Анларына да ичмасам сатин күлмәк, яулыклар да ефәк кирәк. Баш кодага тагы намазлык аз. Баш кодагыйга тагы төп кодагый белән берочтан булмый ярамый»,— диде.

Шул уйларны суза-суза, бирнәләрнең төсләрене, кыйммәтләрене уйлый-уйлый, базга төште. Андагы каймаклар, майларны, тозлы ит, тозлы казларны күздән кичерде. Тагы ике тозлы казны юкка сатуы өчен үкенп, хезмәтчеләргә иртәгә сөтне бирмәскә уйлап, өйгә керде. Өйне җыйды, җыештырды. Мәҗлесне кая ясауны уйларга тотынды: «Сәкене чыгарсак, түргә муллалар, ишек төбенә ил картлары, бүлмәдә никях тыңларга кодагый, кодачалар, башка табыннар — келәткә! Бәлешләргә табалар җитәрлек булмаса да, туйда күрше-коланнан алу да гаеп түгел. Беренче мәҗлескә ике бөлеш бирергә кирәк. Муллаларга катышкач, мулла әбисе булгач, ахрысы муллаларча булырга кирәк! Аштан сон мулла хатын кеби иттереп җимеш суы ясарга кирәк. Кода-кодагыйларга сумсаларны ак оннан эшләргә кирәк. Бертөрле таба ашы гына бик прастуй була, коймак та кабартасың. Лэкин, әле шул, тагы килен уңмаган! Җаныңны тындырып таба ашларын рәтли белми. Былтыр карт муллаларда иртәге чәйдә ашаган кеби вак пәрәмәч ясасаң, аны серкә белән бирсәң шәп булыр иде дә, әлеге килен! Казны бозмасак та, итне турап чыгарырга кирәк. Мулла-мөәззин белән катышкач, мужик төсле затсыз булырга ярамый. Кием-салым, әлхәмделиллаһ: кодагый белән ашка чыкканда бикәч вакыттагы җон күлмәкне киярмен, өйдә каршы алганда — киленнең бирнәсен. Затсызрак иңде дә, анлар шул мулла-мөәззин белән катышып гомер үткәрмәгән. Аш-су өчен килен сөлге-салфетыы тотар. Аны ни өчен алганнар! Затсызның кияү муллага йөз сөртерлек сөлгесе дә юктыр инде. Никях мәҗлесе көнне ике тәкә суярмыз, ирләр мәҗлесенә азрак тозлы ит тә кушып бирергә ярый. Ит аз калып китсә, хатыннар мәҗлесенә берәр тутырган тавык та

бирермез. Май йитәрлек икән әле. Мулла кияү, бәлки, туң майны яратмый торгандыр, аңар коймак, сумсаны сары майдан пешерермез. Быел катык-сөт әлхәмделиллаһ. Менә муллалардагы кеби катырган корт ясасаң иде. Абыстайдан барып сорашыйм: «Абыстай, түбән авылның мөәззиненә кызымызны сорадылар, хәзрәт бик дога кылсын, менә шул садакага тулы ният чыксын, үзең дә догада бул, сабак кызың иде» — диярмен дә, абыстайга өч тиен садака биреп, кортны ничек ясауны өйрәнермен. Килендәш муллалардагы кеби кортны күреп исе китсен! Хәер, ул аның кадерен беләмени? Ул затсыз бит, бәрәңге ашап гомерен үткәргән. Мулла-мөәззин белән алыш-биреш иткәнмени? Менә кара инде өе нинди! Килен дисәң килен. Каенанасының өене ничек җыештыра. Кунак-фәлән килеп төшсә, сөлге, тастымалы ни төсле? Үзеңә тиң йирдән кыз алмагач шулай була шул инде! Галәветдинем йөдәтте, юк исә безгә, әлхәмделиллаһ, шәһәрдән дә бирүчеләр бар иде. Тукта, буңар карап торырга ярамас, ичмасам ак оннан бераз күмәч кабартып куйыйм, өч-дүрт йомыркадан гына булса да кош теле, юка пешереп алыйм».

— Кызым, кызым! Саҗидә, Саҗидә! — дип, кызыны чакырырга тотынды. Кызы кергәч, бик йомшак иттереп кенә кызын күздән кичерде. Аңар кызы, шул, унсигезгә кадәр кадерләп үстергән кызы кызганыч, аяныч кеби тоелды. Мәрфуга абыстайның күзенә яше килеп тыгылды, ләкин күңеленә мөәззингә соралуы килеп төшкәч, аның ихтыярсыз авызы елмайды. Аның күңеленә шатлык тутырды. Ул, тагы йомшак кына иттереп:

— Җиңгәңнең кулы-башы катып беткәндер, аш-су янына китерерлек тә түгел, бигрәк лыкырдык. Менә өч-дүрт йомыркага гына кош теле пешермәкче булам, кулыңны юып кына камыр әвәлә әле, муллаларга кунак-төшем буласы, имеш, чәйгә-фәләнгә алып керелсә, бер нәрсә юк,—диде.

Саҗидә, почта юлаучы атларынң кыңгыравы кадәр зур чулпысыны чалтыратып, исле сабын белән кул юарга чыгып китте.

Мәрфуга абыстай тагы: «Менә, Аллаһе Тәгалә бәхетене бирсә, мөәззин хатыны булыр, ил буеңда кадер-хөрмәт күреп йөрер. Аллаһе Тәгалә

сәламәтлек бирсә, баласы-чагасы булыр, шәкерте мәдрәсәгә китеп укыр. Бу елда инде мулла угылы дип тормыйлар, мөәззин угылыны да мулла ясыйлар. Атасы-анасына дога кылыр. Бу мужик халкының затсызлыгыннан йөдәдем инде. Әле бит килендәшем бай хатын булган булып һаваланган була. Беркөн муллалар мәҗлесенә бит ашка катык катып чыгарган! Мәрхүм каенанам яратмый иде, белмәенчә түгел шул!» — диде.

Уй артыннан уй китте. Кош теле пеште, өй җыештырылды.

***

Көтүләр чыкканча хезмәтчеләр белән урманга киткән Галәү бөтен йортны балта шакылдавы, пычкы чыжлавы белән тулган тапты. Ул үзенң былтыр көз сөя-сөя кискән бүрәнәләренең, тегермән ясарга дип җыеп куйган юкәләренең кайсысы киселеп ташланганыны, кайсысы балтачының рәхимсез балтасы астында елап ятканыны күрде. Үзенең тегермән ясарга дип өч-дүрт ел җыелган туры, төз агачларына каршы аның күңелендә кызгану хисе уянды. Үзенң әллә ничә елдан бирле уйлап килгән тегермән салу планыны булдырырга вакыт йиткәч кенә бозулары өчен эче пошты, ачуы килде, каршы чыккан хатынна каршы:

— Самавыр, самавыр! Тизрәк! — дип кычкырды. Хатыны:

— Әллә минем дүрт кулым бармы? Элгәре осталарны ашаттым, аның артыннан иген сугучылары өлгерде, инде син кычкырасын,— диде. Галәүнең күңеленә хатынның хаклы икәнлеге фикере килсә дә, ул ирлек итеп:

— Лыгырдама! Тиз бул! — дип, тагы кычкырып куйды. «Иген сугучылар» дигән сүз тагы аның исене китәрде: «Бунлар нишләгәннәр?! Тегермән ясарга дип хәзерләгән бөтен бүрәнәләрне кисеп бетереп мунча буратала! Фәхри малайларының шул тегермәннән генә унике җанлы җәмәгатьне тәрбия кылып торганнарыны белмиләр. Ел да борай төшеннән генә тегермәнчегә капчык-капчык он калдырганыны сизмиләр дип белерсең! Тагы, шуның өстенә, иген суктыралар. Нәрсәгә кирәк? Әллә ашарга-эчәргә

беттеме? Берәр ай үтеп китсә, ике сука арасында бит сугар идек тә, ике ай көткән өчен бер потка ике пот алыр идек»,—диде.

Шул ямьсез уйлар белән ул, өсттән-өсттән генә юынып, өйгә керде. Чәй янына утыргач: «Нихәл, угылым, урман нишли?» — дип чыккан атасына каршы, хурланган тавыш белән:

— Сезгә кирәге бармыни? Минем өч ел тегермәнгә дип җыйган бүрәнәләремне кистертеп әрәм итеп ыргыткансыз. Ул бураның нәрсәгә кирәге бар? — диде. Мәрфуга абыстай:

— Алай сөйләмә, угылым. Менә сине өйләндердек. Хатынңнан уңмасаң, безгә үпкәләмә, (шул сүзне әйткәндә, бүлмәдә самавыр өрә торган киленнең зур чулпылары, протест ясаган кеби, шалтырап куйдылар) үзеңә үпкәлә. Менә кызымыз да йиткән, белмәссең, язмыш булса...—диде дә, бик зур мәгънәле сүз әйткән кеби, шул сүзнең нинди зур тәэсир каддырганыны күрер өчен, угылының йөзенә карады. Галәү һаман ачулы көенчә:

— Йитсә җитәр. Кыз җитте дип, кабыктан чыгып, тегермәнгә дигән бүрәнәләрне әрәм итәләр димени? Әле шул мунча ярамаган димени? — диде.

Мәрфуга абыстай, бик зур кыйммәтле сүз әйткән кеби, акыртын гына:

— Мулла-мөәззин шул синең кара мунчаңа кереп йөрмәс инде,—диде дә Галәүнең күзенә карады.

Галәү мунча салуның, ашлык сугуның мәгънәсе нәрсә икәнен аңлаган кеби булды. Шул уйга каршы килгәнене кырыгынчы мәртәбә белдерер өчен кеби:

— Без үземез мужик, безнең киявемез дә үземез кеби мужик булыр. Безгә яраган өй, безгә яраган аш-су, безгә яраган мунча анар да ярар. Эт чаба дип, бет чаба дигәндәй, безгә муллалар артыннан йөрергә иртә әле,— диде.

Мәрфуга абыстай тагы:

— Сеңелеңнең бәхете булса, нишләрсең соң? — диде. Галәү, ачулана-ачулана чәй эчкәнен дә сизми калып, ындырга китте. Анда баргач, атасынң ике кибәнне дә сугарга кушканыны белеп, коты очты. Галөүнен тырышлыгы-тырмашлыгы белән еллар буенча җыелган шул байлыкны, әллә нинди мулла-

мөәззиннәргә иярергә теләп, бер-ике көндә бетерергә теләүгә каршы аның күңелендә әллә никадәр дошманлык хисе уянды. Атасы белән тагы берничә каты сүз әйтешеп алды. Аның күзе чалгы астын кибәнгә таба тырмый торган бер малайга төште. Ул:

— Кая итәсең, малай, кая итәсең? Иген күрмәдеңме әллә? — дип кычкырды. Аның күңелендә тагы шул үзенең маңлай тире белән җыелган ашлыкка каршы мәхәббәт-кызганычтан мөрәккәб бер хис уянды. Ул, үзен үзе сизмәенчә дә, эшкә катышып китте.

Ашлыклар сугылып беткәч, Галәү бераз тынп киткән кеби булса да, беркөнне өйләдән соң арбадан ясаган трантас җигеп, әтисеннән калган читекне киеп, җәйге май ае булса да, камалы тунын киеп, янына зур кама бүрекле, әдрәс тышлы, тамак эчле камзол кигән хатынын утыртып, Түбән авылның Шәрәфи абзый килеп төшмәсенме! Галәү, бизгәк белән изелеп ята торган кешенең аркасына кинәттән суык су салынган кеби, җылылы-эсселе булып китте. Аның сеңерләре бик нык булса да, башына кан йөгерде, колаклары яна башлады. Ул, аяк баскан йире тайган кеше кеби булып, аптырап калды. Ул кунакның атын алып туарып куйды. Хәерчене урынтын тешләргә теләгән эт кеби, үзе Шәрәфигә каты сүз әйтергә, каты мөгамәлә кылырга хәзерләнә башлады.

Кунаклар килү — тагы андый-бундый гына түгел бит, баш кода кунаклар килү — Садыйк абзый, Мәрфуга абыстайның түбәләрене күккә күтәрде. Анлар ни кылганнарын оныттылар. Садыйк абзый, мөәззин бабасы буласын сизенме, Шәрәфи абзыйны «мулла Шәрәфи абзый» дип эндәшә башлады. Мәрфуга абыстай да киң битле, кечкенә күзле кунак хатынын мулла хатыннарыннан олуглап, өрмәгән урынга утыртмады. Аш-су бары да ак оннан эшләнде. Кичкә таба бәлеш тә өлгерде. Ахшамнан чыгуга, килен яңа мунчаны да томалап кайтты.

Кунаклар янына иртәге чәйгә ак он сумсасы, ак он коймагы белән муллалар да чакырылды. Бүлмәгә кунак абыстай янына мулла хатын белән Сиражиның Зәйнәбе өндәлде. Шәрәфи абзый рәсми сурәттә яучы булып

килгәнен аңлатты. Бүлмә ягында да кунак абыстай мөәззиннең анасының яхшылыгыны, бала җанлылыгын сөйләргә кереште. Бер тәкә итене ашап бетереп, яучылар: «Киңәшеп-уйлашып карыйк, базарда хәбәр бирермез» — җавабын алып, килгән юлларыннан киттеләр.

Галәү, яшеннең бик якын икәнен сизенеп, шулкадәр тырышлык белән җыелган малның әрәм булырга вакыты йиткәнене күреп, атасы-анасы белән тагы чынлап сөйләшергә тотынды. Ул элгәре яхшылык белән үзләренең мулла-мөәззингә катышырлыклары юклыгыны, мулла-мөәззингә Саҗидәнең ярамавыны сөйләде. Ләкин Саҗидәнең мулла-мөәззингә ярамавы сүзене ишеткәч тә, атасы да, анасы да:

— Сиңа үз хатының гына кеше инде, безнең кызымызны да мыскыл итәсең,— дип бәйләнделәр.

Галәү тагы мулла-мөәззиннең бунларның кызына түгел, байлыкларына кызыгуларыны, анларны тәрбия кылырга байлыклары йитмәүләрене сөйләде. Ләкин шул мөнтәкый сүзләр мөәззин әбисе булу уе белән шашкан Мәрфуга абыстайга да, мулла-мөәззин арасына кереп, «мулла Садыйк» исеме белән эндәшелергә гашыйк булган Садыйк абзыйга да һич тәэсир итмәде. Авылның таза, нык байларыннан санала торган Әхмәдинең угылыннан килгән яучы да, авылның яңа гына кибет ачып сату итә башлаган, бердәнбер башы белән эшкә керешкән шактый сумалы Гарифулланың баш кодасы да анларны шул фикердән кайтара алмады. Базар көнне «Аллага тапшырамыз» дияргә карар бирелде.

Баш көнне, акча салырга дип, тагы теге Шәрәфи абзый килде. Тагы аш-су ясалды, мәҗлес җыелды. Акча салырга вакыт җиткәч кенә, Шәрәфи абзый, Садыйк абзыйны читкә алып:

— Әле бит мин акча салырга килдем дә, миңа акча бирмәделәр. Аны, кода, берәр эш эшлик, мәҗлес яме өчен берәр хәйләсене булдырыйк, беләсең, мулла-мөәззин халкы акча биреп алырга яратмый,—диде.

Садыйк абзый, «шулай, шулай» дип, карчыгы янына чыгып китте. Ләкин шул беренче адымында ук бунлар өстенә салынган мөәззингә каршы

әллә нинди бер шөбһә уянды, «Галәүнең сүзләре тугры булмасын» дигән фикер килде. Ләкин Мәрфуга абыстай аны май кеби язды:

— Алай ярыймы соң, карт. Анларның әле мәшәкатьле елы, безнең әле, әлхәмделиллаһ. Алай да анларга шактый күп чыгыш булыр әле. Акча бардыр бит. Шәрәфи кодага биреп тор, ул бит барыбер безгә кайтачак! — диде.

Садыйк абзый Шәрәфи кодага утыз тәңкә акча санап бирде. Мәһәр ике йөз сум булырга, Мәрфуга әбинең сыеры эчендәге чуар тана язылырга, Садыйк абзыйның алачагы читек-кәвеш, камзул, түшәк-ястык белән йөз илле сумы тәмам, илле сумы мөәҗҗәл булырга сүз беркетелде. Карт мөәззин хатынның үлек өстеннән килгән өр-яңа җон яулыгына төреп акча салынды. Мулла кияүгә ике пар күлмәк-ыштан, ике пар балтыр чүпрәк, ике пар сөлге, баш кодага намазлык, каенанага намазлык, күкрәкчә-күлмәклек, кодача бикәгә, күлмәккә башка, мулла кияүгә дип, бер тутырган тавык, бер кадак чәй, әллә никадәр сумсалар, кодагыйга дип, зур-зур күмәчләр, һәйбәт бәлешләр, пешкән очалар бирелде. Һәм дә, мулла кияү догада булсын дип, Мәрфуга абыстай теге пар каз саткан өч сумны һәм дә, кодагый абыстай ният укысын дип, әбисеннән калган талир тәңкәне садака итеп җибәрде.

***

Туй якынлашты. Галәү сугылган игенне ике ат белән базарга ташудан туктамады. Бүлмә тулган кызлар кияү күлмәк-ыштаны, бикәч күлмәкләре тегүдән бушамадылар. Мәрфуга абыстай иртәдән алып кичкә кадәр туй ашлары хәзерләүдән арына алмады. Бөтен өй кайнады, бөтен йортның асты өсткә килде. Шул мәшәкать, шул эш эчендә, Галәүнең мыгырдавы да ишетелмәде. Эшнең күплегеннән киленнең зарлануы да колакка кермәде. Туй якынлашканнан якынлашты. Садыйк абзый никях мәҗелесе өчен әйберләр алырга шәһәргә барырга булды. Кесәсендә акчасы булса да, ул тагы ике йөккә арыш төяргә кушып, карчык белән ниләр алырганы уйлашырга чәй янына утырды.

— Нәрсәләр кирәк, карчык?

— Белмим инде, карт. Әле син алып кайткан бер капчык оным бетмәгән, әллә йитәр дә. Туй-төшем арасында борай катыштырырга булмасак, бер капчык кына он ал! Аннан ары, бу как-төшкә, ди, Фәридә әйтә: «беренче сорт кирәк, бу ярамый» ди, «май сикерүчән булыр» ди. Бер кечкенә генә капчык алсаң, йитәр. Как-төш катырырга бал буннан, Сираҗилардан гына алырмыз, анысын алмасаң да ярый. Кодаларга чәй янына куярга, муллаларны чакырганда куярга гына, белмим инде, варенье-фәлән алсаң? Мулла-мөәззин белән катышкач, коры шикәр бит кызык булмас! Йомыркам бар инде. Йитмәсә, бунда тирә-күршедән дә табып була, аны шәһәрдән ташып йөрмәссең инде. Май шактый күп әле. Фәридә әйтә: «Как-төшкә биш кадактан артык май китмәс, сумсага, катламага да шулкадәр җитәр»,—ди. Кияүгә бүләккә дигән как-төшне хәзерләгәнчә әле бит бармый тормассыз. Шуның өчен, кода-кодагыйлар өчен, мәҗлес өчен генә дип ал. Ярты пот, утыз кадак булса, йитеп торыр. Бәлеш йимеше дә бетмәгән әле. Никях мәҗелесендә теге саран хәерче Миңнеколлар кеби өч-дүрт йимеш куеп кына чыгару килешмәс бит, карт, үзең мулла-мөәззин белән кода булсаң? Төшлесене биш-алты кадак, бик теләсәң инде, ун кадак алсаң җитәр. Төшсезе биш кадактан артык булмасын! Инде бетте дә бугай. Бер-ике кадак чамасы гына как-төш өстенә сибәргә чәчәкле кәнфит алырсың. Фәридә әйтә: «Ул ике төрле була, ди, берсе вак, ярма кеби генә, ди, берсе ире-ире, кына чәчәге кеби»,—ди. Онытма, ике төрле! Ит-аш арасында күңел болганып-фәлән итеп китмәсен дисәң, бер-ике дистә лимон алырсың. Мулла-мөәззин белән катышкач, куас-сыра пешерү затсызлык була инде. Иртәге чәй янына кай вакытларны муллаларны алып керсәң, Сираҗины чакырсаң, «затсызлар, мулла-мөәззин белән катышалар, чәй яннарында эфлисун да юк» димәсеннәр дисәң, ун-унбиш данә генә эфлисун да ал. Аннан инде, карт, әле бит муллаларда аш артыннан бер тәмле су бирәләр? Шуны мин Фәридәдән сораштым, ул коры чия икән. «Шуны Садыйк абзый өч-дүрт кадак алса бөтен туй-төшемгә йитәр»,—ди. Тагы инде, бетте. Белмим тагы, үзеңнең күзеңә бер-бер затлырак нәрсә чагылса, алырсың әле.

— Бүләкләр, бирнәләр?

— Әйе, карт, әйе. Бүләк, бирнә дә, аласы әйбер дә юк инде. Әлхәмделиллаһ, кызымның сөлге-салфеты баштан ашкан. Садрый кызы кеби, килешкәч кенә урам буйлап сөлге-салфет эзләп йөрергә булса нишләр идең? Кодагыйга бит инде, кәшимир күлмәк дигән идек, кызыл кәшимир алырсыңмы, алнымы инде? Затлырак булсын. Баш кодагыйга да, кодагый белән берочтан ук булмаса да, җон булсын дидек бит, карт? Яшь кеше түгел инде, кырык итәклене кими торгандыр, ундүрт-унбиш аршин булса җитәр. Ике иңле булса, карт, тугыз-уннан артык алма! Кодачага, карт, һәйбәт кенә, зур гына җон яулык ал. Аллы-гөлле кирәкмәс, керәшен хатыннарынкы кеби чуклы булмасын! Җон яулыкның матуры булмаса, ошатмасаң, ефәк яулык та ярар. Кодача мулла-мөәззингә китмәгән әле, аңар иңде күлмәге, карт, җон булмаса да ярар. Йә шунда ефәк төсле сатин була, шуны алырсың, йә бик матур берләнтиннәр була, әнә мулла хатынныкы кеби. Ул яшь кеше инде, карт, аңар аршин исәбе күбрәк булсын. Алай да унсигез-унтугыз аршиннан артык булмасын. Белмим инде, иңе генә бик тар булмаса? Анда үзең карарсың инде. Тагы, карт, кодагыйның тутасы бар ди бит. Ул: «Мин карт иңде, туйга бара алмам, бирнәсе булса рәхмәт инде»,—дип әйткән, ди. Мулла-мөәззингә катышкач, карт, аны да буш итәргә ярамас инде. Аңар күлмәк-фәлән алып тормассың, курыкма! Алты чирекле зур җон яулыклар була, карт, карчыклар өчен диярсең. Шул ярар. Күкрәкчәсен, сөлге-салфетын буннан гына куярмыз. Инде бетте бугай. Белмим инде, әллә авылларының мулла хатынына бүләк иттереп кодагый остазбикә артыннан бернәрсә йибәрсәк? Бергә остазбикә булып ил буенда ашка йөриячәкләр бит. Аңар инде затлы гына бер ефәк яулык булса йитәр. Күрмәгән, белмәгән кешегә, йитәр, йитәр, карт! Мулла кияүгә дип инде бит үзең сөйләгән идең, карт, ләкин Фәридә әле әйтә: «Шәһәрдә, ди, кияүгә сәгать, постау чикмән бирәләр»,—ди. Минемчә, шул, казакилек, тагы бу елда бит инде, яшьләр чалбар да кия. Шул, казакилек, чалбарлык алсан йитәр. Син инде аны, карт, үзең генә алма. Әхмәтсафаларның кияүләрене-фәләнене алып барып, сайлап ал. «Мулла-мөәззин белән катыша белми,

затсыз»,— димәсеннәр. Кияү күлмәк-ыштаннарымыз, әлхәмделиллаһ, бар: чиккән якалысы да, челтәрле якалысы да баштан ашкан! Мин әле мулла хатынннан белмәгән булып кына сорашып утырдым да, ул: «Муллаларда ак палатнадан гына тегәләр, анларда чиккән яка кию юк, ул мужик гадәте»,— диде. Мин дә: «Без дә шул әле кияү муллага актан эшлимез»,— дидем. Минем сүзем ялган чыкмасын инде, карт, син күлмәк-ыштанлык алып кайт. Нечкә генә, нәфис кенә булсын! Өч күлмәк-ыштанлык булса ярар. Кызлар бик тиз тегеп бирерләр. Шуның белән бетте инде. Сәҗидәгә кияү катына керергә дигән аллы җон күлмәкне, кияү арасында алыштырырга дигән бер сатин, бер яңа — сарпинкә кеби бар бит әле? — шуны алырга үзең дә хәтереңнән чыгармассың инде. Аңар башка бернәрсә дә кирәкми инде: яулыгы җитәрлек, читеге-кәвеше өр-яңа. Белмим инде, берәр калфак-фәлән генә алмасаң? Калфагы барын бар да, Фәридә әйтә: «Мулла-мөәззин өчен бу бик затлы түгел»,— ди. Ислемай-фәлән, мунчага куяр өчен хуш исле сабын-фәләнне үзең белеп алырсың инде. Әле мулла хатын: «Туеңыз кайчан?» — дип, бик сорашып утырды, «Сәҗидә минем сабак кызым иде»,— ди. Никях вакытында бирнә арасында аңар бер нәрсә дә булмаса, күңеле калмасын, дим. Сәҗидә бит инде шул мулла хатыннары белән йөрешәчәк кеше инде. Хәзрәткә дә шунда, кияүгә алганда кушып кына алырсың, биш-алты аршин палатна әллә нәрсә түгел! Инде бетте! Карт, тагы ашамлык-эчемлектән тәмлерәк, затлырак нәрсәләр булса, саклап тотарга гына азрак алырсың. Әчеткесене, чүпрәсене инде Галәветдин генә алыр. Кодаларга гына эчерергә дип, белмим инде, алты пар гына яхшы чынаяк, чәйнек, алты гына тәрилкә алсан? Әнә, карт мөәззин хатынында бар бит, карт? Шуның кеби булсын! Чынаяклар ал булса, тагы затлы булыр. Тәрилкәнең агы затлы, ди. Муллаларда бит һәрвакыт ак тәрилкәләр! Кияү муллага пәрәмәч, коймак ашарга вак тәрилкәләр дә күзеңә чалынса алырсың. Анлар очсыз була, ди. Кыйбат бирмә! Әнә Фатыйма остазбикәдә бар бит, лимун кисәргә дә ярый? Мулла халкы пешкән каймак яратучан була, диләр. Шуның өчен әледән үк иртәге сөттән генә бер-ике әвәстән каймак кайнатып куйдым. Мулла-мөәззин алдына, карт, савытка салып кертү, бит, затсызлык булыр. Очраса, матур гына,

пөхтә генә каймак савытлары була, шунда аңар кушып, чәй түбе салырга касәсен дә калдырма инде. Кияү янына куярга савытта бик тәмле кәнфитләр була да... Әле кияү кергәнчә, бит, барырсыз. Кодаларга инде теге калай савыттагы түгәрәк кәнфитләрне генә алмасаң? Бетте бугай инде. Акча калса, белмим инде, миңа, кодагыйлар белән илгә-көнгә чыгарга дип, бер күлмәк кенә алмасаң? Бик акаеп тора торган булмасын! Аксылрак булса да ярый. Минем бала-чагам юк инде былчыратырга! — диде.

Садыйк абзый атка утырып чыга башлагач: — Карт, тагы күзеңә затлырак нәрсәләр чалынса, кызыңа бер-бер бүләк, кияү муллага бер-бер нәрсә алып кайтырга онытма! Саҗидәгә укалы башмак булса да ярый. Кияү муллага сәгать ал димим инде, син ала белмәссең, Әхмәтсафаларның кияүләре алышса, чылбыры җуанрак булсын! — дип кычкырып калды.

Садыйк абзый, шунларны онытмас өчен яулыгының бөтен очларыны төенләп бетереп, шәһәргә китте. Галәү шунларга акча йиткерер өчен, теге ике йөкне шыгрым итеп төяп, өстенә базарда җыелган тиреләрне куеп, атасы артыннан китте. Туй якынлашты.

***

Авылның күзгә күренгәнрәкләре һәммәсе никях мәҗелесенә чакырылды, тирә-яктагы атаклырак муллаларга ат йибәрелде, мөәззиннәренә шәһәрдән алып кайткан путаллы язулы өндәү кәгазьләре күндерелде. Һәрнәрсә, һәр эш затлыча кылындырылды. Туй өчен атап тектерелгән әдрәс камзулдан, очлы башлы кәләпүштән Садыйк абзый хәзрәтләрне үзе каршы алды. Ул хәзер, үзенең искедәге кеби тирече Садыйк абзый түгел, мулла бабасы Садыйк абзый икәнен аңлату өчен кеби, һәр килгән кешегә каршы килеп, элгәреге кеби, дорфача иттереп: «Әйдәңез, Гайни, әйдәңез, Нәби, әйдәңез, Габдерәш»,— димәенчә, «Рәхим итеңез, рәхим ит, Гайнулла абзый, рәхим ит, Нәбиулла кода, рәхим ит, Исрафил кияү, рәхим ит, Габдерәшит»,— дип каршы ала иде. Тегеләр дә хәзерге Садыйк — әүвәлге Садыйк түгел икәнен сизенгән кеби: «Исән торамсың, Садыйк? Сәламәт кенәмесез, Садыйк абзый?

Арумысез, Садыйк кайнагай?» дияр җирдә: «Сәламәтме сез, Мөхәммәтсадыйк? Саумысез, Мөхәммәтсадыйк агай? Хушмысез, Мөхәммәтсадыйк кайнагай?» — дип эндәшәләр иде.

Хатыннар ягында эш тагы башкача иде: анда киң җон күлмәк, бөтен тәңкәләрдән, ахаклардан тулган киң хәситә кигән, өр-яңа зур, җон яулык бәйләгән Мәрфуга абыстай элгәреге Мәрфуга абыстайга — ире юк вакытта ит үлчәп бирә торган, тавык йомыркалары өчен күрше хатыннары белән орышыша торган Мәрфуга абыстайга бөтенләй башка иде; шул зур вакыйга аның сыйфатыны үзгәрткән кеби, телен дә башкарткан иде; ул кияү мөәззиннең анасына бер «кодагый абыстай», бер «кодагый бикә» дип кенә эндәшә, аның үлгән мөәззине хакында сөйләшкәндә: «Менә кода хәзрәт кенә исән булмады. Аллаһе Тәгалә угылының шатлыгын күрергә язмаган икән. Ничә еллар булды инде, кодагый абыстай, кода хәзрәтнең үлгәненә?.. Алай икән. Мулла кияү бик яшьли калган! Син, кодагый абыстай, шулай укытып мулла кияүне зур дәрәҗәгә җиткерергә мәшәкатьләнгән икәнсең!» — дия иде. Сүз андый-бундый прастуй эшкә, сыер-сарык, йорт-йиргә кереп китсә, ул тагы шул сүзне йөпләүче хатыннарга югартын гына иттереп: «Мескеннәр, мулла-мөәззин күрмәгән, кодагый белән сөйли дә белмиләр»,—дип, анларны кызгана да, тагы кодагыйны үз тирә-янында яшәтер өчен: «Кодагый абыстай, кода хәзрәтне бик гыйлем кеше иде диләр, тавышы бик һәйбәт иде диләр»,—дип, тагы китапчага бора иде. Бундагы һәммә нәрсә, һәммә эш хәзер затлы булырга тырыша, һәммә кеше муллаланырга маташа иде.

Никяхтан соң Садыйк абзый, затлырак булыр өчен, бөтен мәҗлескә садака өләште; никяхтан соң, муллаларга охшасын өчен, Мәрфуга абыстай, бик зур кактөш чыгарып, дога кылдырды.

Ашлар, сыйлар — һәммәсе муллаларча үтте: ак оннан ясалган пилмәнне ике төрле вак бәлеш алыштырды, бәлешләрдән соң, муллаларча иттереп, серкәле-керәнле тураган ит (мужикларча турамаенча чыгарган түгел), аның артыннан затлы йимеш суы, иң ахырдан ясап чыгарылган лимунлы чәй бирелде. Чәй янына баягы как-төш чыгарылды. Бирнә күрсәтелде.

Хәзрәтләр шактый күп алган туй садакасыннан, авыл кешеләре тәмле иттереп ашалган ашлардан, кода-кодагыйлар яхшы бирнәләрдән, Садыйк абзый, Мәрфуга абыстай мәҗлеснең муллаларча — затлы үтүеннән разый калдылар. Барысы да шатландылар, сөенделәр.

Авыл халкының гадәте буенча, никяхтан соң ук кияү алырга барырга булса да, Садыйк абзый, кемгә катышканыны бик белгәнгә, туйны затсызландырып, кодалар өстенә кияүне китертмәде. Ул, муллалардагы кеби, кодалар, кодагыйлар киткәч, бер-ике көн үткәч кенә кияү хәзрәтне алдырырга булды. Шуның өчен, кодалар китү белән ул тагы кияү сыйлар өчен шәһәргә китте.

Белмәгән-танымаган кияү муллага ят күренмәсен өчен, бунларның нәселләре мужик икәнлеге беленмәсен өчен, ул бер ике-өч төрле варенье, өч-дүрт төрле савыт кәнфит, биш-алты дистә лимун, әфлисун, җәйге вакыт булса да, алма бәлешенә-фәләненә дип, унбиш кадак алма, алма кибетендә күргән берничә төрле коры җимеш, аннан соң, күрше авылның Сәлим хәзрәт кенә эчә торган кадагы ике ярымлык ише чәйдән бер кадак чәй һәм дә үзләренең муллаларында ишан хәзрәт килгәндә генә бер ике-өч бөртек кенә салына торган яшел чәйдән ярты кадак кына чәй, Сажидәгә сөртер өчен өч-дүрт төрле генә ислемай, тагы вак-төяк нәрсәләр генә алып кайтты.

Мәрфуга абыстай яңадан ак өйне, мунчаны юдырды, бөтен баскычларны, өйалдыларын пакьләтте, кияү муллага куярга дип, яңадан как-төш пешерде, катырды, яңадан пешкән каймак кайнатты.

Менә кияү алырга барырга көн җитте. Мәрфуга абыстай Галәүгә:

— Кияү мулланың хәтерен калдыра күрмә! Андый-бундый тупас сүз әйтеп затсызлыгыңны белдермә! Синең хатын ягың бик затсыз бит, күп сөйләмә! Юлда сораган сүзенә генә җавап бир. Читегеңне менә шулай ки, сызырылып төшмәсен! Синең хатыңның соң иренә балтыр чүпрәге дә юкмыни? Кияү мулла алдында кычкырып сөйләмә. Атларны кауларга тугры килсә, дорфа иттереп, сүгенеп кычкырма, «Һай, хәйван! Һай, хәйван! Алланың

рәхмәте төшкере, һай!» дип кенә кычкыр,— диде. Аннан соң киленне чакырып:

— Әйтмәсәң — белмисез, әйтсәң, каенанам усал дип зарланасыз. Мулла кияү килә. Мунчасы исле булса, мунчасы парсыз булса, буның гаебе бит сезгә түгел, миңа! Ашыңның тозы-тизе чыкмаса, яисә, Таракан хатыныныкы кеби, шыр тоз булса, аның да ояты миңа бит! Шуның өчен әйтәм инде, нишләгәнеңне белеп кенә йөр. Шарт-шорт басып, солдат кеби кылынма. Килешми, килен! Мулла кияү түрендә ятса, син дөбер-шатыр аның йокысын качырсаң, ул нигә ярый инде? Башыңа шәл салмаенча чыкма! Ирең белән, хезмәтче белән кычкырып сөйләшмә! Шул имгәк балаңны бертуктамаенча җылатма! Иртә торганда мунчаң хәзер булсын! Кияүләр кайтканда самавырың кайнаган булсын, коймагың пешкән булсын! Мулла кеше син дә без түгел, коймакны табадан төшә-төшә генә бир! — диде.

Садыйк абзый үзе дә кем белән эш иткәнене белсә дә, Мәрфуга абыстай аңар да:

— Син, карт, иртә торып чыгасың да: «Килен, килен, комганга су сал!» — дип кычкырасың. Берсе-берсе тире күтәреп килсә, аның белән кычкырып-кычкырып сатулашырга тотынасың. Ул элгәре ярый иде, хәзер түреңдә кияү мулла ятканда алай килешми, карт. Ул, беренче килгәндүк: «Бу нинди затсызлар икән!» — дип китәр. Кияү алдында кияргә дип үзеңә резинкә калуш алып кайт дидем, син һаман әле шул кәвешең белән такт-токт йөрисең, сак булырга кирәк! — диде.

Бөтен йорт-җир, бөтен кешеләр кияү көтәргә тотындылар. Бөтен кешеләр ярты тавыш белән генә сөйләшә башладылар.

Менә, түбә өстеннән, өч атлы тимер ходның тузан туздырып якынлашканы күренде. Бөтен өй «жуу!» итеп китте. Мәрфуга абыстай, тагы барысына да әмерләр биреп, кызының өстенә өч-дүрт төрле ислемайдан яртышар шешә актарып, кияү көтәргә чыкты.

Менә кыңгырау тавышы ишетелде. Авылга керделәр. Садыйк абзый, әдрәс казакиене киеп, капка төбенә чыкты; ак күлмәк, яңа чабата кигән

хезмәтче капканы тотып тора башлады. Аллы-гөлле бикәчлек шәлен ябынып, килен чыгып, ишек бавын тотты. Мәрфуга абыстай, кияү мулланы чынлабрак күрер өчен, чоланга кереп ишекне япты.

Кыңгырау якынлашты. Капка ачылды. Шалдыр итеп килеп трантас ишек төбенә туктады. Трантастан иң әүвәл Галәү сикереп төште, аның артыннан Садыйк абзыйның кияү бүләгеннән тектергән казаки-чалбарын, үзенең мәдрәсәдәге иске җиләнен, авылларындагы яшь мулладан алган кара бүрекне, Мәрфуга абыстай биргән өч тәңкәгә алынган читек-кәвешне киеп, шунлар өстенә бунлар биргән сәгать чылбырларын матур иттереп са-лындырып, кечкенә, ябык кына кияү мулла төште. Ул, кулына тоткан кечкенә генә сандыкны күтәреп, Садыйк абзый белән күрешеп дога кылды. Аннан соң ашыга-ашыга ишеккә таба борылды. Ишек бавындагы киленгә тәһлилдән килгән яулыкны биреп, ишек артында югалды...

***

Икенче көнне Мәрфуга абыстай иртүк торды. Аягының очына гына басып, киленне уятып мунча ягарга кушты. Көтү чыга башлаганны күреп, көтүгә ашыкканлыкларын белдерер өчен кычкыра торган сарыкларны, кияү мулланы уятмасыннар дип, тизрәк чыгарып йибәрде. Үзе коймак өчен куйган апарага тәмлерәк булсын өчен тагы бер-ике йомырка сытты. Сумса камыры катырак кеби булганга, аңар иртәге сөтнең имчәк тәбен кушып атлады. Кырга китәргә ашыгып йөри торган Галәүнең хезмәтчегә: «Малай, тизрәк бул. Атлар җик!» — дигән каты тавышын ишетеп, камырының өстен дә капламаенча, йортка чыгып, ярты тавыш белән генә, намаз укый торган кешенең намазыны янлыштырмас өчен кеби генә иттереп:

— Галәү, Галәү! Бәпкәм, акыртын! Кияү мулладан оял! — диде. Зур чиләкләр белән мунчага дип су күтәреп кайтып, «ларт» иттереп чиләкләрен утырткан киленнә каршы:

— Әй затсыз, әй затсыз! Шул чикле шакылдарга ярыймы соң, кияү мулла йоклаганны белмисеңмени? — дип орышырга тотынды. Килен

орышуның ләззәтенә кереп китеп, Мәрфуга абыстай аз гына үзе дә кияү муллaның барлыгын онытып кычкырырга тотынмады.

Кояш шактый күтәрелде. Мунча өлгерде. Эссесе йомшак булсын өчен, Садыйк абзый, бер-ике чүмеч кенә пар салып, чабынып чыкты. Коймак кабарып йитте, сумса камыры кабарып кире кайта башлады, пәрәмәч тышлары ясалып бетеп, майлы таба да кызарга хәзерләнеп җитте. Сүрән генә иттереп аш өенең миче дә ягылды. Кияүләр өендә тавыш-тын чыкмады.

Сәгать сигез булды. Кияү мулладан элек чәй эчү әдәпсезлек булса да, Мәрфуга абыстай чәйсез түзә алмады. Ул үзенә генә кечкенә чәйнеккә чәй пешерде. Эченнән: «Аллаһе Тәгалә Саҗидәне мәхәббәтле күз белән күрсәткән булсын!» — дип, дога кыла-кыла чәй эчәргә утырды, ләкин күзен кияүләр өчен акырын гына кайнап тора торган, кияү сыйларга алган ак самавырдан, колагын кияүләрнең өйләреннән алмады.

Менә кияүләрнең өендә җан галәмәте сизелде. Әллә кемнең йомшак кына идән буйлап атлау тавышы колакка керде. Мәрфуга абыстай, тагы аягының очы белән генә басып чыгып, йортта маташа торган киленне кул изәп кенә чакырды. Киленнең килүе белән:

— Бар, тордылар бугай. Шәлеңне салып кына ишек төбенә бар, чибәр абыстаңа әйт! — диде.

Килен, зәңгәр шәлне салып, падишаһ янына кергән кеби генә калтырап, ишекне акыртын гына тартты. Ишек, бигенә бәрелеп, азрак шылтырап китте. Өйдә сөйләшкән тавыш ишетелде. Менә акыртын гына атлап ишеккә килгәнне сизенде. Ишек ярык кына ачылды. Килен кызарганрак йөздән бераз оялганрак кыяфәтле чибәр абыстайны күрде. Анларның күзләре очрашты. Саҗидә елмайды, тагы кызарды. Килен:

— Мунча хәзер, торган булсаңыз, барыңыз. Тыштагы казанда ару су, эчтәге казанда юыну суы,—диде.

Бераз вакыт үтмәде, шәл ябынып, оялганлыктан күзене түбән таба төшереп, Саҗидә, казакидән, ыштан өстенә генә яланаякка кигән кәвештән мулла кияү мунчага таба киттеләр.

Анларның артларыннан ук килен бик тиз кереп урынны җыештырырга тотынды. Урынга салган тишекле сиксәнлекне алып, түшәкләрне кабарта башлады, шул арада кергән Мәрфуга абыстай, әллә ни караган кеби, киленнең кулыннан күзен алмады. Килен, шуны сизенгән кеби, түшәк япмаларын акыртынрак, яшеребрәк алырга маташа башлады, ләкин вакытның тарлыгы белән әллә нишләп аптырап китте, каенанасының булуы тагы каушавын арттырды. Ул, үзе сизми дә, түшәк япма астыннан әллә нинди чүпрәкләрне коеп җибәрде. Мәрфуга абыстай шуны гына көтеп торган кеби:

— Әлхәмделиллаһ, әлхәмделиллаһ! Аллаһе Тәгалә мөхәббәтләрене бирсен! — диде дә чыгып китте.

Килен кызара-кызара, тиз-тиз урынны рәтләп, кичә калган чынаякларны, аш-суларны җыеп алды, идәнне себерен бетереп, самавыр кертеп куйды, һава алырга бер тәрәзәне ачты.

Менә киткән кеби үк иттереп кайтып килә торган кияү, бикәче күренде. Башын түбән игән Сәҗидә, бите кызара төшкән кияү мулла да, кешедән качкан йомран кеби, елт итеп кереп югалды.

Аш өендә ике таба мич буйлап йөрергә тотынды. Килен иң әүвәл сары майга гына коймакны салды. Ул кызарып өсте килгәнчә пәрәмәчләрне тутырып, Фәридә күрсәткәнчә азрак шурпа салып, анларны мичкә тыкты. Мәрфуга абыстай үзе казанда сумса пешерергә тотынды. Өйгә пәрәмәч, коймак чыжлавы белән тәмле бер ис тулды. Мәрфуга абыстай, базга төшеп, пешкән каймак алып керде. Килен беренче таба коймакны алды, пәрәмәчләрнең урыннарыны үзгәртте. Казанда да беренче салыш пешеп өлгерде. Коймакның өстенә тагы сары май салып, килен тагы шәлене ябынып, бер тәрилкә сумса, бер савыт каймак күтәреп, кияүләр ишегенә китте. Ишек ачылды. Сәҗидә тагы коймак, сумсаны, каймакны алды. Килен пәрәмәчләрне ала башлады. Ул анларга тагы шурпаларыны салып, бер кулына кияү сыйлар өчен алынган пыяла савыттагы серкәне күтәреп китте.

Тагы ишек шакылдады, ишек ачылып, пәрәмәч эчкә китте.

Садыйк абзый, чынаягы каты шалтырамасын дип акыртын гына куеп, чәй эчүендә дәвам итте. Аның борынына да пәрәмәч, коймак, сумсаның тәмле исләре керсә дә, кияү муллага аз булмасын дип, ул аны алырга өмет итмәде. Икенче табалар да китте, өченче табалар салынды; ул да китте. Мәрфуга абыстай, кияү муллага азрак булмаса ярар иде дип, шөбһәләнә башлады. Менә тагы сумса кертелде. Саҗидә:

— Бунда булды инде,—диде.

Калган бер ике-өч сумсадан баядан бирле карга кеби авызыны күтәреп тора торган киленнең угылына берсе, Садыйк абзыйга берсе, Мәрфуга абыстайга берсе тиде. Коймак беткәнгә, аның тәмене берсе дә татый алмады. Пәрәмәчнең тәме дә исенең яхшылыгыннан гына сизелде. Килен иртәдән бирле чәй эчмәсә дә, ул бик тиз мичне җыеп, берсе дөгедән, берсе тавыктан, берсе кич өчен ике-өч бәлеш ясап тыкты. Садыйк абзыйның бүген суйган тәкәсенең очасыннан гына Мәрфуга абыстай үзе казан асты. Яшь тәкәнең тутырмасыны каймак, дөге, бавыр атлап үзе тутырды. Галәүнең угылы, сумсаның тәмен сизеп, тагы ашар өчен җыларга тотынса да, әбисе: «Тик тор, мулла җизнәң колагыңны кисәр!» — дигәч, ашыйсы килсә дә, ул да туктады. Садыйк абзыйның да эчендә йөгереп йөрсәләр дә, ул да кияү муллага аш өлгермәс-фәлән дип чыдарга булды.

Мичтә эш беткәч тә килен мунчаны җыеп, мунчага салган кызыллы юллы сабынны күтәреп кайтты. Ул чәй эчмәкче булып самавыр яңартырга өлгермәде, хезмәтче белән Галәү кызып-янып кайтып керделәр. Галәү йортка керү белән хатыныны шәл ябынган көенчә күреп:

— Әллә бүген төштеңме, шәл ябынып йөрисең? Самавыр тизрәк, тизрәк самавыр! — дип кычкырды.

Мәрфуга абыстайның коты очты. Ул тагы аяк очы белән генә басып чыгып:

— Галәү! Угылым, угылым! Акырын! (Теге өйгә күрсәтеп.) Кияү мулла бар, кияү мулла! — диде.

Сусаганнан эче кипкән Галәү, бер сүз дәшмәсә дә, дошман күзе белән түр өйгә карады. Килен үзенә дигән самавырны анларга бирде. Чәйдән соң аш ашау гадәтләре булса да, кичке кадәр кыр эшендә ашамаенча торырга мөмкин булмаса да, Мәрфуга абыстай:

— Казан буш түгел, угылым, менә шунларны ашаңыз,— дип, бер савыт катык, кичә кияүләрдән калган бәлешнең капкачыны китереп бирде.

Галәүнең угылы: «Әти, мин дә ашыйм!» дип, бәлеш капкачының яртысыны атасыннан алды. Галәү ачу белән, ашаганыны да сизмәенчә, катыкны бетерде. Тамак аз гына да туймаганга, ачуланган тавыш белән хатынына:

— Әллә бер-бер нәрсә хәзерләргә ярамас идеме? Өйдә ятып аш та хәзерли алмыйлар! — диде. Килен:

— Чү, чү, шаулама! Үзең ашадыңмы, дип сора. Кичәдән бирле авызыма бер локма куйганым, бер чынаяк чәй эчкәнем юк,—диде.

Галәүләр тагы киттеләр. Тагы өй өрәкләр төсене алды, тагы тавыш-тын бетте.

Менә аш пеште. Килен кулыны юып пилмән ясап алды. Кияү сыйларга алган мискидә элгәре пилмән китте, аның артыннан тавык бәлеше, аның артыннан дөге бәлеше, аның артыннан тутырма белән ит, аннан соң чия суы. Миски төбендә генә калган пилмәнне Мәрфуга абыстай Садыйк абзыйга салып бирде. Ярты төбе калган Тавык бәлешенең ярты капкачыны Галәүнең угылына сындырып биреп, калганыны җыеп куйды. Ярты төбе Киселмәгән дөге бәлешеннән картына бер кисәк, үзенә бер кисәк алып, киленгә ярты капкачыны төртте, өч-дүрт калҗа ит белән дүрт-биш кисәк бәрәңгесе калган итне карты алдына куйды. Үзе:

— Килен, самавырың кайнаганмы? Мулла халкы аштан соң чәй эчүчән була,— дип, самавыр куярга кушты.

Самавыр бирелде. Чәй янына Мәрфуга абыстай, лимун, әфлисунга башка, кичә пешергән алма бәлешен, Садыйк абзый алып кайткан

кәнфитләрдән бер савытыны, бәлки чәй белән кабып эчәргә ярап торыр дип, вареньe янына коры йимешләр төяп керттерде. Аннан соң:

— Килен, каенатаң иртәдән бирле рәтләп чәй эчкәне юк, самавыр куй да мунчаңны барып кара. Мулла халкында кияүне бит кич тә кертәләр. Сулары бармы? Идәнне юып ал, сөлгеләрене алыштыр. Пары беткәндер, аз гына чыбык-чабык белән генә ягып ал! Тиз йөр! Кияү мулланың ашыйсы килә башлар, кичке ашны салырга кирәк,— диде.

Килен тагы ике көянтә су китерде, тагы мунчаның идәнене юды, тагы якты. Юлда: «Ашыйсым килә, сөт бир!» — дип елап тора торган угылын: «Башымны әйләндермә, бетмәссең әле!» — дип сугып китеп, базга төшеп ит алып менде, тагы казан асты, тагы Галәүләр кайтканча дип токмачыны кисеп куйды. Иртә салынган бәлешне йылытыр өчен мичкә кертеп тыкты. Шуннан соң тагы вакыт табып, чәй эчим инде дип самавыр куйды. Ләкин самавыр кайнап өлгермәде, Саҗидә ишекне кагып:

— Җиңги, самавырың юкмы? — диде. Килен тагы самавырсыз калып, мунчаны томалады.

Аш кайнады. Галәүләргә нәрсә ашатырмыз икән дип төшенергә өлгермәде, анлар тагы кайтып керделәр. Килен эш арасында гына тагы анларга самавыр куйды. Мәрфуга абыстай тагы ярты тавыш белән генә:

— Казанымыз буш түгел, кияүләргә аз гына аш астык,—дип, тегеләргә тагы яртышар бәлеш капкачлары бирде. Галәүнең мыгырдавыны, хезмәтченең ашка каравын җавапсыз калдырмас өчен: — Кияү бар бит, беләсез, мулла кияү! — диде дә кереп китте.

Менә, көтүләр кереп, килен сыерлар савып бетермәде,кияүләр тагы мунчага киттеләр. Анлар кайтуга дип, ул тагы самавыр куйды. Чәйдән сон, баягы кеби үк итен, тагы элгәре шурпа, аннан ары бәлеш, аннан ары ит, аннан ары йимеш суы, аннан ары самавыр бирелде. Шунлар беткәч, каенатасына тагы самавыр куеп биргәч, килен иртәгә мунчага ягарга утын илтте. Каенанасына коймак, сумсага коярга йомырка, он, сөт кертте. Анасының сыер савып сөт бирүен көтә-көтә ач көенчә йоклап киткән угылыны урынга салды.

Бераз эш беткән кеби булганга, үзенең бүген иртәдән бирле чәй эчмәгәнене дә хәтерләп, самавыр куйды. Үзләре ята торган келәткә чәй урыны хәзерләп, сөт, икмәк илтте. Ятарга барырга дип киткәндә чәй-шикәрне алып китмәкче булып өйгә керде. Кияүләр өеннән ишек шакылдады. Бер төен күтәргән Сәҗидә:

— Менә, җиңги, бунлар кияү бүләге. Менә, самавырга ут салып кына куй, җиңги, бераздан үзем алырмын,— диде.

Килен бүләкләрне чыгарып бирде. Үзе тагы самавыр куйды.

Бүләкләр арасында Галәүгә иске хәтфәдән тегелгән бер кәләпүш, Мәрфуга абыстайга үлек өстеннән килгән җон яулык, Садыйк абзыйга күлмәклек ситса, киленгә зур француз яулык, угылына кызыл саплы пәке, дуст-иш кызларына бирер өчен сабыннар, кершәннәр чыкты.

Килен каенатасы, каенанасының комганнарына су тутырып, ятарга китте.

Икенче көнне дә вакыт шулай үтте. Өченче көнне дә, казан буш булмаганга, Галәүләргә аш булмады. Эш күпкә килен чәй эчә алмады.

Шул көй белән тугыз көн үтеп китте. Тугызынчы көнне кияү китәргә теләсә дә, Мәрфуга абыстай, муллаларча булмас дип, унберенче көнгә калдырды. Ләкин, ак он бетеп киткәнгә, Садыйк абзый авыл сатучысыннан гына он алып килде. Икенче көн дөге беткәнгә, Мәрфуга абыстай киленнән генә дүрт-биш кадак кына дөге алдырды. Кодагыйга бүләк иттереп сала торган бәлешкә йимеш йитмәс кеби күренгәнгә, бераз җимеш тә китертелде.

Зәгыйфь кенә, ябык кына килгән кияү кызарып-тулып китте. Галәүләр, хезмәтчеләр, зинданнан чыккан кеби, иркенләбрәк суладылар, атка, сыерга иркенләбрәк: «һай, һау! Туча!» дип кычкыра ала башладылар. Иң зурысы — уникенче көнендә эштән кайткач кайнар аш ашый алдылар.

***

Өч-дүрт көн үткәч тә Мәрфуга абыстай:

— Карт, мулла кияүне алдыруны уйлый башларга кирәк, синең хәтереңә дә кереп чыкмый. Ул бит мужик кияве түгел,— дип туглый башлады.

Бишенче көнне аны ике йөк белән иген төятеп, азрак кына он, дөге, йимеш, чәй-шикәр, лимун, әфлисун, коры җимеш, варенье, кәнфитләр, вак-төякләр алырга шәһәргә йибәрде. Тагы мунчалар, идәннәр юылды, тагы кияү мулланың килүенә дип Фәридә чакыртылып, яңа кош теле пешерелде, яңа пешкән каймак кайнатылды. Тагы өч ат җиктерелеп кияү мулланы алырга йибәрелде, тагы килен көненә ике кунак ашы хәзерли, көненә алты самавыр бирә башлады, тагы эштән кайткан Галәүләргә, казан буш булмаганга, коры-сары бирелә, көн буе авыл буеннан сарык алып, тире җыеп йөри торган Садыйк абзыйга калдык-постык ашатыла башлады. Тагы килен көн буе ач тора башлады. Тагы бөтен өй өрәкләр тора торган сарай кеби тавышсыз-тынсыз яши башлады. Тагы атнаның соңында шәһәргә баручылар артыннан биш-ун кадак кына май белән бер кадак кына чәй, ярты пот кына беренче он алдырырга тугры килде. Тагы ун көн үткәч кияү, бөтен хәзерләнгән нәрсәләрне ашап бетереп, кайтып китте, тагы Галәүләрнең авызларына кайнар аш тиде.

***

Өченче килүдә программа башкара төште. Кияү мулла белән Саҗидәне Мәрфуга абыстай илгә-көнгә чыгарасы килгәнгә, иң әүвәл абыстай белән хәзрәтне кияү чәенә чакырды. Чәй белән генә йибәрү яхшы булмаганга, билгеле, килен бәлеш тә ясап тыкты. Мәрфуга абыстай үзе аскан яңа тәкә шурпасына токмач та кисеп салды. Икенче көнне сатучы Сираҗиләр хатыны белән чакырылдылар, «үземезнең Фәхретдиннәр» дә кичке ашка өндәлделәр. Киленнең атасы затсыз булса да, Галәү күңеле калмасын дип, кодагый белән ул да дүртенче көнне ашка алдырылды. Бишенче көн, алтынчы көн дә кунаксыз калынмады. Ләкин бу мәшәкатьләр бушка чыкмады: мулла кияү белән Саҗидәне парлап ашка чакыра башладылар. Мәрфуга абыстай иң әүвәл хәзрәтләр чакырсалар иде дип бик теләсә дә, үз кызының хәзрәтләр белән йөрешкәнене күрәсе килсә дә, беренче Сираҗиларга барырга тугры килде.

Аннан соң бик ялынып чакырганга, затсызрак булса да, кодаларга барырга вәгъдә бирелде.

Бу көннәрдә эш кими төшәр дип килен тынычланса да, хезмәтче белән Галәү казан бушар дип шатлансалар да, Мәрфуга абыстай, ашта ашаганга ышанып кунакны ач калдырмыйм дип, һаман ике аш ашатудан туктамаганга, икесенең дә өметләре бушка чыкты.

Кияүләр кунакка чыга башлау белән Галәү өчен тагы бер уңайсызлык артты: суканың иң кызу вакыты булса да, ике сабан белән сукалап тизрәк икешәрләргә керешергә теләсә дә, кияү мулла остазбикәсе белән урам буеннан селкенеп җәяү йөри алмаганга, бер ат һәрвакыт өйдә калдырылды. Тагы кай вакытлар аштан соң кыр карап кирәселәре килгәнгә, трантасны һәрвакыт майлап хәзер итеп тотылырга тугры килде. Эшнең иң кызу вакытында кайнар ашсыз атналар үткәрү никадәр авыр булса да, атын алып аны кулсыз кеби калдыру тагы авыр тоелды. Ул:

— Кем булганнар? Әллә хан угылы белән хан кызымы? Җәяү бара алмаслармыни? — дип каршы тормакчы булса да, Мәрфуга абыстай:

— Угылым, ни сөйлисең? Кияү мулламы? Кияү мулла авыз селкетеп урам буенча җәяү йөрсенме? Син аны Әхмәди малае дип белдеңме? — дигәнгә, Галәү, никадәр сөйләп, суканың катыга калуын исбат итәргә теләсә дә, бер мәгънә чыкмады: ат калды, казан бушамады, җир ката килде.

Урак өстендә дә кияү сыйлау белән мәшгуль булганга, килен өйдән китә алмады. Коры-сары белән торудан туеп беткәнгә, хезмәтче качып кыр ягына китте. Бөтен кырда Галәү үзе калды. Элгәреге елларда үзләре ура торган җирләрне дә кешегә бирергә тугры килде. Эшнең иң кызу вакытында гына, орлык өчен көлтә китерергә тотынганда гына, он бетте. Кияү сыйлый-сыйлый сата килгәнгә, тарттырырга арыш беткәнгә, Галәүнең бабасыннан бер йөк арыш потка пот алынды. Алай-болай көлтә кертеп орлык ясарга өлгермәделәр, тагы кияү килүенә оны-тозы, мае-чәе, дөгесе беткәнгә, ике йөккә төяп, яңа арыш белән Галәү базарга китте. Урак кыйбат булганга, биреп урдырырга

дигән акчалар кияү сыйларга киткәнгә, Садыйк абзыйның бу ел урагы муллалардан да соң бетте.

Уҗым кыры чуарланып беткәндә Галәү беренче чәчү белән чыкты. Чәчүгә чынлап кереп китеп тәменә генә йитә башлаганда тагы мулла кияүне барып алырга кирәк булды. Тагы ике көн бушка үтте. Ул, шул бушка үткәннәрне түләр өчен, көне-төне сөрә башлады. Ләкин өйгә кайтканда аш булмау, шул ашсызлыкның җәй буе баруы аны көчсезләтте: ул кыйнап ташлаган кеби булып арып, иртәгесен урынннан калка алмый башлады. Килен дә эштән чыкты: ул, һәр көнне ике мунча якса да, башын уарга вакыты булмаганга, бетләде, кер юарга көне җитмәгәнгә, Галәү дә, үзе дә икешәр атна алмаштырмаенча кия килгәнгә, бөтен өст-башлары кергә, былчыракка батты. Вакытында ашатучы, караучы булмаганга, Галәүнең угылы да чуаннар, кычыткылар чыгып авырды. Садыйк абзый да әллә нәрсәгә бөкерәя төште. Кияү мулла гына өшәнмәде: ул тазарганнан тазарды, кызарды, тулды.

***

Ашлык яхшы уңган булса да, Садыйк абзый, кибән калдырсаң да файда итеп булмый, җәй бәһасе кыйбатрак булса да, аның өлешен генә тычкан да кисеп бетерә дип, кибән калдыра алмады. Кияү мулланы тәрбия кылу, кияү мулланы сыйлау аның югын ашаганга, сарысын сауганга, аның хәле чагайганнан чагайды.

Мәрфуга абыстай гына үзгәрмәде. Ул хәзер бөтенләй башка җырлар җырлый иде: ул мужик халкының мулла-мөәззинне карамавыннан зарлана, гошер биреп малыны хәлалләмәенчә ашавына ачулана, ил-көндәге бозыклыкларны шуннан күрә, хатын-кыз мәҗелесендә «гошерсез мал хәрам була-фәлән» дигән сүзләрне мулла хатынннан да еш ычкындыра иде. Ул, дөресте дә, кияү мулласына быел булган сигез арба гына гошергә ачулана, шул затсыз авылның мужикларын тирги, мужикларның шул оятсызлыкларына исе китә иде. Шул гошердән сүз чыкканда ул:

— Карт, болай калдырырга ярамый, анлар яшь кешеләр бит, әллә никадәр кирәкләре бар. Гошереңне чыгармасаң мал хәлал булмас,—дип, төгән дип, картны, бигрәк Галәүне, кияү муллага гошер бирергә, муллага биргән кеби, җилдән соң урылганнан начар гына бер арба түгел, тәмам гошер, ун арбага бер арба бирде-рергә тели иде. Мулла кияү юк вакытта аны Саҗидә дә куәтли иде. Ләкин Галәү:

— Бунда гошере-мөшере калмады инде, ике кибән арыш ашап бетерделәр. Хәзер инде яңа ашлыкка тотындылар,— дип, тавышын күтәреп сөйләргә тотынса да, Саҗидә, абзасына үпкәләп, аш ашамаенча теге өйгә чыгып китә, Мәрфуга абыстай:

— Алай ярыймы соң, угылым. Кияү муллага каршы алай итәргә Алладан курык! Мулла-мөәззин ризасы — Алла ризасы диләр, телең корыр! — дип куркыта иде.

Галәү теле коруына ышанмаса да, шул, бунларга килгәндә чыра кеби килгән, хәзер сабан туенда көрәшергә тазартыла торган башкорт кеби кызарган мөәззиннең догасыннан-фәләненнән курыкмаса да, кычкырышып торырга күңеле бармый, тагы кулын бутап, атасы кушканча кияү муллага гошердән дип кибән куя иде. Ләкин кияү, өйләнгәненә өч-дүрт ай үткәнне сизмәгән кеби, һаман әле хатынны өенә алырга теләми, ул һаман әле айның егерме көнен бунда үткәрә иде.

Көн үткән саен Мәрфуга абыстай үзгәрә бара иде: ул суярга дип алынган сыерны:

— Бик матур икән, Саҗидәмә булыр. Карасана, карт, имчәкләре! — дип, суйдырмаенча калдыра, кыр ягыннан трантас җигеп кайткан Әбәли малаеның трантасын да:

— Карткаем, бигрәк матур икән. Карасана, өр-яңаласак. Кара, котсыз, нинди ямьсез иттереп, трантасны ямьсезләп утырып йөри. Саҗидәгә булыр, картым, алыйк,— дип, аны да алдыра иде. Бөтен авылдан каз йоннары, мамыклар җыйдырып, «Саҗидәмә булыр» дип, мендәрләр ясата, Галәү, карты барган саен базардан әле Саҗидәмә мендәр тышлыгы, әле Саҗидәгә тәрәзә

пәрдәсе, әле Сажидәгә чаршаулык, әле Сажидәгә чыбылдык алдыра иде. Ләкин җыену һаман бетми иде: атна саен яңа кирәк мәйданга чыга, атна саен Сажидәнең җиһазының тулмаган җирләре күзгә күренә иде.

Сабан ашлык сатылгач, Мәрфуга абыстай:

— Мулла кияү Сажидәне алырга сораса, карт, нишләрмез? Син бернәрсә белмәгән кеби торасың. Ничек итеп кызымны шул иске өйгә төшерик! Ичмасам шунда урыс арасында йөргәндә карый йөр: юнь генә, яхшы гына беткән өй булмасмы? Бурадан салдырырга бик озакка китәр бит,— дия башлады. Садыйк абзый, элгәре үзенң кесәсе саега башлаганыны күреп, ул кадәр тирән кермәскә теләсә дә, Мәрфуга абыстай:

— Ни сөйлисең, карт?! Ничек яшь кешеләр каенана өендә торсыннар?.. Ярый торган вакыты бар, ярамый торган вакыты бар. Хәзер остасы да очсыз була, мүге дә юнь була,— дия иде.

Галәү тагы каршы килә, тагы мыгырдана, тагы аңар карамаеңча эш башлана иде.

Менә шулай итеп өй дә эшләнә башланды. Сажидә кунакка барганда өйне яратып кайтты, ләкин кайткач та:

— Әти, шунда калдык-постыктан мунча да ясат инде. Мунчалары юк, күршегә йөрү бик уңайсыз,— дияргә өлгермәде, Мәрфуга абыстай:

— Ясатырмыз, кызым, ясатырмыз,— диде.

Кияү муллага йорт салдырырга, Сажидәгә җиһаз хәзерләргә шактый күп акча кереп киткәнгә, Садыйк абзый бу елны җирне дә күп алмады, дөресте — ала алмады. Ул тагы кешегә сөйләгәндә: «Игеннән дә файда юк, ел көтәсең, ярый ла Алла бирсә, булмаса нәрсә? Акчаң, хезмәтең әрәм була!» — дигән булып юрамакчы булды.

Өйләр беткәч тә кияү мулла Сажидәне бөтенләй алырга булганга, Садыйк абзый тагы кызу-кызу шәһәргә йөрергә тотынды. Ул шактый йомшаган булса да, сер белдермәс өчен, Сажидәгә ак самавыр, яхшы чынаяклар, яхшы тәрилкәләр, мискиләр, кашыклар, ике җиз комган, зур бакыр таз, зур һәйбәт сандык алып кайтты. Ләкин Мәрфуга абыстай:

— Ай карт, ай карт! Ирләр әйбер ала белми шул. Бу самавырны көн дә куярга ярыймыни? Кырык тиенлек чынаякны көн дә тотарга ярыймыни? Син инде аны, алган-алганда кала, шунда тагы алты пар гына ак прастуй чынаяк, алты гына тәрилкә, анысы унике булса да ярый, бер дюжина гына кашык, кечкенә, ике-өч кешелек кенә прастуй самавыр алалар,— дип каршы алды.

Садыйк абзый, чыннан да әйбер ала белми икәнен тасдыйк итеп, икенче барганда шунларны да алып кайтты. Сыер биргәч, ат бирми килешми инде! Галәү, никадәр бирдермәскә теләсә дә, бу ел гына дүрткә чыккан айгырны бирергә килешелде. Биш баш эре сарык бирергә булды. Тагы, казы-үрдәге хатын-кыз эше булганга, Мәрфуга абыстай, ирләргә киңәш итеп тормаенча, икешәр оя каз, үрдәк, унбер-унике баш тавык бирергә дип, суйдырмый калдырды.

Туй көне сорарга кияү мулланы алырга киттеләр, ләкин кияү килер алдыннан Сәҗидә, әллә нәрсә, авырып китте. Кияү килгәч торып чыкса да, ул аш төрлеләтә, кайвакыт коскалый да башлады. Мәрфуга абыстай:

— Каенана өстенә ничек болай йибәрәсең, сыеры бар, сарыгы бар. Кышкы суыкта өйрәнмәгән кеше йөкле көенчә ничек карар,—дип бәйләнде. Кияү муллага:

— Син инде, мулла кияү, риза бул, җәйгә, Алла теләсә, алырсың,— диде.

Садыйк абзый эченнән озатырга теләсә дә, кияү мулла юри генә иттереп:

— Сезнең сүздән чыкмыйм инде, әби, сезгә бик мәшәкать булды инде,—дигәч, Садыйк абзый да:

— Үз балаң үзеңә мәшәкать булмый, мулла кияү, гаепли генә күрмә. Кадер-хөрмәт итә алмадык,—диде.

Шуның белән Сәҗидәнең төшүе җәйгә калдырылды. Җәй көне каз, үрдәкне кайдан табып булыр соң дип, Мәрфуга абыстай, анларга аталган анларга булсын дип, кош-кортны суймый калдырды.

Кышкы суыклар керде. Мулла кияү һаман, элгәреге кеби, айның егерме көнен бунда үткәрде. Ләкин һәрвакыт барып алырга уңайсыз булганга, кияү мулланың үзенең аты булмаганга, айгырны бирергә карар бирелде. Галәү башка атларга төяп ике йөк печән илтте. Кияү мулла үзе киткәндә, астына гына салып, ике капчык солы, атка бутарга бер капчык он алып китте.

Язга таба өсәкләрдә ашлык бетте. Кияү мулланы сыйларга он-тоз алыр өчен сабан ашлык орлыгын сатарга тугры килде. Орлык беткәндә атларга бутарга он, хезмәтчегә ашатырга икмәк бетте. Чәчәргә орлык булмады.

Садыйк абзый, күп чәчүдән файда юк дип, тагы бер-ике дисәтинә йирне сатып, орлык алды. Калганына тагы, Мәрфуга абыстайның әйтүе буенча, Саҗидәгә күлмәклек алып кайтты.

Җәй булды. Саҗидәнең кызы туды. Мулла мөәззин баласы бит, мужик баласы түгел! Бала аты кушу мәҗлесенә Мәрфуга абыстай ничек тә кодагый абыстайны алдырасы килде. Иске запас беткән булганга, Садыйк абзый үз сарыкларыннан дүрт башын суеп, илтеп сатып, мәҗлескә әйберләр алып кайтты.

Бала туе бик матур үтте. Кечкенә остазбикәгә әллә никадәр бала ашы, иксез-чиксез күлмәкләр, хәситәсенә кадарга тәңкәләр килде. Мәрфуга әбисе бик матур бишек эшләттерде, коендырыр өчен бик һәйбәт җиз таз белән җиз комган алдырды, мулла кияүгә бала бүләге дип Садыйк абзыйдан яңа читек алдыртты.

Саҗидә терелеп йитте. Туйга яңадан хәзерләнә башладылар. Мәҗлес ясарга, бүләкләр алып китәргә тагы вак-төяк нәрсәләр кирәк булганга, сер сынатмас өчен, Садыйк абзый бер атны сатмакчы булды. Чынан да ашлыкны быел ул кадәр күп чәчмәделәр. Нәрсәгә юкка ашатып торырга! Әйткән сүз эшләнде: ат сатылды.

Туй бик шәп үтте. Алдан күрше авыл боярыннан алган повозкада кияү мулла белән Саҗидә китте, арттан дүрт йөктә әйберләр китте. Сыер, сарык, бунлар белән бергә барып керсен өчен, алдан ук җибәрелде.

Туй төште.

***

Кияү киткәч йорт бераз тынганрак булып калды. Хезмәтче белән Галәүгә дә аш казаны бушады. Киленнең дә өстен-башын юарга, керен чайкарга вакыты булды. Садыйк абзый да, шул бер елда чыгарылган малларны кертер өчен кеби, берәмләп булса да, рустан сарык алып кайтып суя башлады. Галәү яңа гайрәт, яңа куәт белән тегермән салыр өчен бүрәнәләр кисәргә тотынды. Мәрфуга абыстай гына иске хәленә керә алмады, ул иртә белән чәй эчкәндә:

— Ай балалар, сез менә нинди рәхәтләнеп ашыйсыз, эчәсез, минем күңелем урынында түгел, Саҗидәм хәзер нишли икән? Мулла кияү өйдә микән? — дип сөйли башлый, яхшырак сарык суелса:

— Мескен кызым белән мулла кияү генә булмады, ите нинди яхшы,— дигән сүзе белән ашны тозлый, шәһәрдән бер-бер тансыграк нәрсә алып кайтылса, мулла кияү белән Саҗидәмә булыр дип, җәмәгатькә күрсәтмәенчә яшереп куя иде. Саҗидәләрнең авылларына баручы бер-бер хатынны ишетсә, ул, кичтән үк авыл сатучысыннан гына он алдырып, ачы күмәчләр сала, биш-алты гына вак бәлеш ясый. Садыйк абзыйдан өч-дүрт кенә лимун белән ярты кадак кына чөй китертә, янына һәйбәт кенә тавыкны тултырып, пөхтә генә төреп:

— Мулла кияү дога кылсын, кызым сәламәт булсын! — дип, бүләк йибәрә иде. Илгә-көнгә кунак килсә, ул:

— Шунлар белән бергә үтәр иде, карт, мулла кияүләрне алдыру кирәк иде,—дип, картының башын әйләндерә, кай вакытларны беркемнән дә сорамаенча, күрше малаена өч йомырка биреп ат җиктереп алырга йибәрә иде. Анлар килгәч, ул тагы әллә кайдан май да табып ала, пешкән каймак та була, лимун, әфлисун да чыгара иде, итсез-нисез чак булса, бер дә кызганмаенча, иртә дә, кич тә тавык суя, акча булмаса, иртүк Садыйк абзыйны йибәртеп, бурычка гына он, май, дөге, җимеш тә алдыра иде. Атна буе урманда кунып-туңып яткан Галәүгә кече атна көн мунча ягарга утын булмаса да, иртә белән,

элгәреге кеби, кабартма пешерергә май, он булмаса да, мулла кияү дигәч шул нәрсәләр һәммәсе бердән табыла, һәммәсе хәзерләнә иде.

Ләкин җәй үткән саен бу елның былтырдан аермасы барлыгы бик беленә иде. Ун-унбиш елдан бирле төбе күренмәгән он, ашлык өсәкләреннән әллә кайчан җилләр исә иде. Сыртлары кайда икәнлеге югалган атларның да кабыргалары саналып тора иде. Һәрвакыт таза киемдә йөри торган Садыйк абзыйның да өсте майланган, Галәүнең дә оеклары ертылган, киленнең дә күлмәкләре сизерәгән иде.

Шунларны күреп, Галәү өч кеше кадәр эшли, Садыйк абзый элгәрегедән ике өлеш артык гайрәт белән сату итә иде. Ләкин килгән файда, эшләгән эш һаман уела бара, Садыйк абзыйның он алырга дигән актык биш, сумы мулла кияүнең йорт тирәсенә такта алырга җибәрелә. Галәүнең өч атна маташып черткән мунчаласы да мулла кияүләрне сыйлар өчен вак-төяк алырга китә иде. Чыгыш күбәйгән саен йорт бозыла бара, фәкыйрьләнә бара, фәкыйрьләнгән саен җитмәгән җир күбәя бара, шул җитмәгәннәрне бетерер өчен, бигрәк кешегә күрсәтмәс өчен, бурычка бата бара иде. Яңа ашлыкка әле шактый ерак булса да, Садыйк абзыйның өе күптән бурычка он ашый, авыл кибетчесеннән чәй-шикәрне яздырып ала, мулла кияүләрне чакырырга булса, тагы бер-ике баш сарык суелып сатыла, яки былтыргы тана иткә әверелә иде. һәр нәрсә кими. Һәр нәрсә эри, мал-туар азая иде.

Көн шулай егыла-тора үткән чакта мулла кияү, йорт-йирне бетереп, йорт котларга кунаклар җыярга булды. Алар, Сәҗидә белән икәү, бабаларыны, Галәү белән җиңгәләрене чакырырга үзләре килделәр. Тагы мулла кияүнең тутасы, мулла кияүнең мәдрәсәдә бергә укыган иптәш шәкерте, Урта авыл мулласы, үзләренең хәзрәтләре дә чакырылганга, кунаклар шактый күп, шактый кадерле булачак кеби тоелды. Сәҗидә әнисенә:

— Кунаклар өчен, әни, эти бер капчык он алсын, бер кадак чәй алсын, биш-ун кадак шикәр янына бер генә савыт варенье алсын. Дөгенең бик вагы булмасын! Берәр көн алдан, әни, үзеңнең генә бер-бер малай артыннан бер суйган тәкә, берне тереләтә — муллалар алган көнне суярга, берәр язым гына

май белән җибәрерсең. Тагы онытканикәнмен: кунак-төшемнең атына бутарга бер капчык кына он да салып йибәр! — диде.

Киявең мулла, үзең мулла бабасы, әбисе булгач, бунларны да тутырырга кирәк булды.

Йортта чыгарырлык бернәрсә дә булмаганга, Садыйк абзый башын кашый-кашый бурычка арыш сорарга китте. Авылның таза кара мужигыннан базарда 50 тиенлек арышны ике айдан соң түләргә 90 тиенгә исәпләп йөз пот арыш алды. Галәүнең сугышып-кырылышып дүрт капчык тегермәнгә чыгарганына башкасын барысын да базарга илтеп сатып, баягы әйберләрне, аннан сон йорт котлап илтер өчен ике зур лампа белән унике пар чынаяк та алып кайтты, мәҗлестә садакага-фәләнгә акча булмас кеби булганга, тиз генә өй тумышы ике сарыкны суеп, итләрен акчага әйләндерде.

Барыр алдыннан гына Галәүнең алыштырырга күлмәге юклыгы, киленнең аягына кияргә кәвеше юклыгы тагы эшне бозды. Ярый әле авылдагы сатучыда күлмәк тә, кәвеш тә табылды.

Барырга ат җиккәндә генә Саҗидәдән мулла кияү кулы белән язылган хат килде. Ул хатында әнисе, әтисенә бик күп газиз гомерләр теләгәннең соңында, кунак-төшемдә кирәк булыр дип, биш-ун сум гына акча алып килергә үтенгәнен белгерткән иде. Садыйк абзый никадәр кызыннан да, кияавеннән дә кызганмаса да, юклыктан аптырап калды. Мәрфуга абыстай:

— Шунда, карт, Сираҗи сатучыдан гына алып тор, бирермез Алла теләсә, игеннәр бит бик яхшы,—дисә дә, Сираҗи сатучыга Садыйк абзый күптән күренергә оялып йөргәнгә, аннан да булмады. Мәрфуга абыстай, кияү мулланың кәефен җибәрмәс өчен, «кияү мулладан яхшы түгел, карт» дисә дә, Садыйк абзый берни дә булдыра алмаганны күргәч, үзенең чәч такмасыны күрше хатын аркылы сатучы хатын Миңнесафага куеп тордырып, ун тәңкә акча алдырды.

Кунаклар юлга чыктылар. Кияү мулла да, Саҗидә дә бик шатланып каршы алдылар. Кодагый гына бераз тынрак торса да, мулла-мөәззин белән катышып, мәҗлесләр бик матур үтте. Ирләр дә, хатыннар да авылның ике

мулласына да кунакка бардылар, авылның бөтен байларына мәҗлескә йөрделәр. Бик зур хөрмәт күреп, дүрт-биш көн үткәреп, кызларының бәхетле булуына шатланып өйгә кайттылар.

***

Бу ел ашлык бәрәкәтсез булды. Сабан ашлык сугыла башлаганча арыш сатылып бетте. Сабан ашлык та ишелеп уңса да, төпсез өсәккә төягән кеби, әллә кая югалды. Кыш уртасыннан ук мал-туарга азык, йорт-җиргә он-тоз беткәнгә, Садыйк абзый сыерны бергә калдырды.

Яз йитә башлагач, язгы налогка туры атны сатарга тугры килде. Сабан ашлык өчен рәтләп җир ала алмаганга, хезмәтче яллап тормаенча, Галәү үзе генә сукаларга тотынды. Бер ат белән генә сабан тарттырып булмаганга, ул әллә кайчан ташланган суканы казып чыгарды. Ул, бик зур оят эшләгән кеше кеби, гөжләтеп сабан белән актарта торган кешеләрнең яныннан акыртын гына, «Алла куәт бирсен»не әйтеп үтә-үтә, үзенең җиренә туктады. Кешеләр ярты көндә бетереп китә торган эшне ул көн ярым, ике көн эшләде, этләнде-нитте, кешедән бер атна калып суканы бетерде. Ике сука арасында тагы урманга кереп, үзенең тегермәнче булу хыялын тутырыр өчен, ачлы-туклы көенчә урманда кунып ятып, агач кисә, мунчала батыра башлады. Ул, шул ике ел эчендә Хозыр кулы белән чыгарылып йибәрелгән дәүләтне үзенең тырмашуы, тырмануы белән генә кайтарырга мөмкин икәнене белгәнгә, шул тегермәнне ясый алса, кыш көннәрендә мал-туарга, үзләренә ашарлык китереп булганга, эш өсте өчен бераз он җыеп калып, әллә никадәр файда итәргә мөмкин булганга, бөтен көчене шуны булдырырга таба борды. Шуның өчен ул, алган агачларыны кисеп бетергәннең соңында, кайсыны валга булыр, кайсыны төпкә булыр дип төпләде дә, берничә агач кисеп, өйгә таба юнәлде.

Юл буенда ул күрше авылның тегермән осталарына кереп, күпмегә эшләп бирүләрен сөйләште. Тегермәнчеләр бик очсыз эшләргә вәгъдә биргәнгә, ул, хатынның бөтен тәңкә-төнкәсен куеп торып, яңа ашлыкка кадәр өлгертергә карар биреп, атасына киңәш итәр өчен ашыга-ашыга өйгә кайтты;

ләкин, ни күзе белән күрсен, былтыр кискән бүрәнәләреннән [җилләр] исә, Галәү никадәр ата-анага хезмәт кирәген белсә дә, ул чыдый алмады: ул бер кешегә дә багышламаенча гына булса да кычкырып-кычкырып сүгенә башлады. Аның сүгенүен Садыйк абзый ишетмәгәнгә салынып, ак якка чыгып китте. Анасы чыгып:

— Чү, Галәү, бәпкәм, кычкырма. Мулла кияүләрнең угыллары бар, ди. Бәбәй туена ни белән бармакчы буласың? Салахи малае алырга теләде дә сатып йибәрдек,— диде.

Галәү көн буе бик озак дәшмәенчә йөрде. Аның башында әллә нинди план туган кеби, ул аяк астына тугры килгән утыннарны, тавыкларны сүкте, угылының: «Әти, әти!» — дип килүенә каршы аны тибеп йибәрде. Кичке чәйдә Мәрфуга абыстайның иртәгә базарга бара торган картына:

— Потлы капчык ак он, ун кадак кына дөге, йимеш, бәбәй бүләге иттереп Саҗидәмә күлмәк, кияү муллага берәр камзуллыкмы, казакилекме нәрсә...—дип, сөйләп бетергәнен көтте дә, ул әллә нинди тавыш белән генә:

— Әти, мин иртәгә чыгам, фатиха бир! — диде. Садыйк абзый катып калды. Мәрфуга абыстай:

— Ничек оялмый сөйлисең?! Атаң-анаңны калдырып чыгып китүне уйларга ничек оялмыйсың? Мулла кияү күзенә без ничек күренермез? — дип, тагы әллә ниләр әйтмәкче булды. Ләкин «мулла кияү» дигән сүз Галәүне, көзән җыерган кеби, астын өсткә китерде. Ул:

— Төкерим мин синең мулла кияveңә! Фидия козгын! — диде дә торып китте. Ул, эчендә яна торган көчне чыгарып бетерер өчен кеби, кызу-кызу кулларыны бутап-бутап, мулла кияүне сүгәргә тотынды.

Мәрфуга абыстай һаман сөйләвеннән, җылавыннан туктамаса да, Галәүнең шул мулла кияү дип йортны бөлдерүләрен сөйләгән сүзе саен Садыйк абзый, шул сүзләрнең дөрестлегенә пичәт баса барган кеби, башыны ия барды. Галәү, берсенә дә карамаенча аш өенә чыгып, хатынына җыенырга кушты, хатынның:

— Кая барасың? Илдән оял! — дигән сүзенә каршы аны бөгеп-бөгеп кыйнарга тотынды.

Кычкырыш-тавыш күтәрелде. Күршеләрнең тәрәзәләре ачылды. Киленне кыйнауга Мәрфуга абыстай эченнән сөенсә дә, урамга ишетелә башлагач, араларга тотынды. Галәү һаман тиресләнеп, үзе әйберләр җыештырып йөри башлаганга, үгетләр өчен Садыйк абзый хәзрәтне алып килде. Хәзрәтнең сүзләрен Галәү һәммәсен кабул итсә дә, ахырдан:

— Мулла абзый, бунлар белән торыр хәл юк. Менә, Алла теләсә, Галәү эшләми дигән сүзне ишеткәнең юктыр, эчә, мал бетерә дигән сүз дә колагыңа чалынганы юктыр? Иртәдән кичкә кадәр эшлим, мулла абзый, йорт булсын дип эшлим, өстемә сорамыйм, алыштырырга күлмәгем юк, мулла абзый! Күлмәгемне юганда кияү күлмәген киеп торам. Хатынмның өсте-башы сәләмәләнгәнене күреп, бабай унике аршин француз алып кайтып бирде, угылыма бабайның иске күлмәкләреннән әби күлмәк-ыштан тегеп китергән. Ашау-эчүемез дә, мулла абзый, шуның кеби: атна буйлап кайнар аш күрмимез, каймак, май, йомырка дигән нәрсәнең ике ел буе төсене күргәнем юк дип ант итсәм, мулла абзый, ханис булмам. Дәүләт беткәннән-бетә бара, кая китә! Мулла кияүнең ак он сумсасы белән пәрәмәч ашавына шул ун еллык хезмәтем кереп китте, мулла абзый. Минем үземнең дә балам-чагам бар, мин ак он коймагын яратмыйммыни? Азрак чаманы белергә кирәк,—диде дә туктады.

Хәзрәт шул сүзләрдән соң тагы әлләниләр сөйләп караса да, Галәү тарафы хак икәнен күреп:

— Садыйк ага, сезгә дә бераз җыенызбрак торырга кирәк. Әлхәмделиллаһ, карамадыңыз түгел, Галәүнең дә сүзләре дөрест бит! — диде.

Садыйк та Галәүнең сүзеннән чыкмаска вәгъдә биргәнгә хәзрәт тә «ил-көнгә мәсхәрә булмаңыз» дип нәсыйхәт иткәнгә Галәү калырга булды.

Иртәгесен кияү мулладан бер йөк арыш сорап хат килде. Галәү никадәр буш йибәрергә теләсә дә, Мәрфуга абыстай тындырмаганга, Садыйк абзый поты бер сумга хисаплап бурычка алып биреп җибәрде. Көзге ашлыкны әрәм иттермәс өчен Галәү әллә никадәр анасы белән оршышты, базарга барганда

кияү муллага кушкан нәрсәләрене берсене дә алмый башлады, анларны алдырырга йибәрә башласалар да, тавыш күтәрергә тотынды.

Кияү муллага бу килешмәде. Ул әллә нәрсәгә үпкәләгән булып, өч ай килми торды, өч ай Сажидәне дә йибәрмәде. Дүртенче айда ул озын хат язып, оннар, итләр, ашлыклар соратты. Галәү өйдә булмаганга, Мәрфуга абыстай шыгрым бер йөк төяп йибәрде. Ул тагы ачылды, тагы кунакка килде. Кыш яртысында ашлык алырга җибәргән малаена Галәү бернәрсә бирдермәенчә:

— Биргәннәренә дога кылсын инде дип әйттеләр диген,—дип буш йибәрде.

Бер атна вакыт үтмәде, балалары белән Сажидә килеп төште. Ул җылап-җылап, атасына, анасына мулласының хурлануыны, шуның өчен Сажидәне кыйнавыны сөйләде, агасы оршышты, аталарына-аналарына:

— Менә орлыкка бер йөк ашлык бирмәсәләр, сукага егерме биш тәңкә акча бирмәсәләр, кайтма, өйгә кертмим!» диде,— дип зарланды.

Галәү:

— Йөз өсте белән китсен! — дисә дә, Мәрфуга абыстай:

— Ни сөйлисең син, Галәү? Мулла кияү...—дип башлаганга, ул:

— Мин актык орлыктан аңар күзенә кырып салырга бер бөртек тә бирмим! — дип, келәтне бикләп алды.

Мәрфуга абыстай тагы тәңкәләрен сатып, чулпысыны закладка салып, унсигез тәңкә акча бирде. Галәү кырга киткәч, орлык тутырырга дип келәткә дә керде. Ләкин Садыйк абзый бу юлы бер капчыктан артык салдырмаганга, аңар күрсәтмәенчә тагы бер капчыктан артык биреп булмаганга, Сажидә ике капчык ашлык, унсигез тәңкә белән генә китте.

Кырдан кайту белән Галәү, дүрт күзе кеби саклап килә торган орлык кимегәнне күреп, тагы тавыш чыгарды. Анасы:

— Хатының урлагандыр,— диде.

Ул, чыдый алмаенча, тагы җыенырга тотынды. Бу юлы ул дуст-ишнең дименә карамаеңча чыгарга булды. Иртә белән, бабаларыннан җиккән ат алып

килеп, ул, әйберләрен төяп, өйгә, этисе-әнисе янына: «Караңыз, бернәрсә дә алмадым!» — дияргә керде. Анарның бер сүз дәшмәүләренә карап:

— Хәерле булсын, дәшәрсез әле,— дип, хатынна кычкырып, угылыны арба өстенә утыртып, капканы ачты. Капка ачылу белән, шуны гына көткән кеби, начар гына арбага көчкә генә селкенә торган бия җиккән, арбасының артына иске сандык куйган, ике ягына ике баласын утырткан, җылый-җылый күзләре шешенеп беткән Саҗидә килеп керде. Ул каршы чыккан әнисенә, күз акайтып калган агасына, җиңгәсенә каршы:

— Аерды! Хәрам хат бирде!..—дип кычкырды.

*Соң.*

**Искәртмәләр һәм аңлатмалар:**

*Итү* — илтү.

*Мәрәккәб* — куушылган, барлыкка килгән.

*Мөнтәкый сүзләр* —тәнкыйть сүзләр.

*Мөәҗҗәл булу* — көтәргә калдыру.

*Как- төш* — чәкчәк.

*Төшенү* — уйлау.

*Чагаю* — начараю.

*Тасдыйк итү* — раслау.

*Вал* — ныгытма.

*Ханис* — антын бозучы.

**Кияү**—Хикәя Казанда «Әхмәтгәрәй Хәсәни вә шөрәкясе» наширлегендә Харитонов типографиясендә 1912 елда басылып чыккан. Сигезтомлыкта: 2 нче җилд, 3 нче китап. 136— 191 битләр. Хикәя «язылган: 17 июнь —5 июль. Истанбул. Кәндилле». Әсәрнең 1912 елның 15 апреленә кадәр чыгуы мәгълүм *(Яңа гына басылып чыккан китаплар.— Вакыт. 1912, 15 апрель).*

Хикәя дөнья күргәч язылган рецензиядә мондый юллар бар: «Хикәядә күрсәтелгән шәхесләр һәр каюсы татар тормышында адым саен очрала торган чын типлар булып, бик матур тасвир ителгәннәр. Хәкыйкатьтә, мәзлум, каенанасының эче пошкан саен аны орышып, талап, үзенә бер тынычлык хасил итә торган хәйван иттереп кенә карый торган килен тибы... бу чын татар килене инде... «Кияү», хәкыйкатьтә, тормыштан алынып, поэтический итеп язылган, геройларның психологияләре һәр каюсы ачык итеп күрсәтелгән. Хасыйле, «Кияү»не укыганда татар тормышын көзгедән караган... кебек күрәсең, рәхәтләнеп укыйсың. *(Татар.— Кияу.— Сибирия. 1912, 22 июль.)*

*Хәситә* — хатын-кызларның алтын-көмеш акчалар, ука һәм төрле кыйммәтле ташлар белән бизәлгән, күлмәк өстеннән күкрәккә киелеп куела торган бизәнү әйбере.

*Хозыр* — легендар пәйгамбәр. Имеш, ул «тереклек суын» эчеп, мәңге яшәү хәленә ирешкән һәм хәерче, көтүче яки юлчы кыяфәтендә изгелекләр эшләп йөри.

Чыганак: Исхакый Г. Әсәрләр. 2 том. - Казан:
Татарстан китап нәшрияты, 1999. Б.186-219.